Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

15 ноябрь, 2021 ел № 3

Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 139 номерлы Надеждино авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Надеждино авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Аркатау авылында. 2021 елның 28 ноябрендә 10.00 сәгатьтә 1 Май урамындагы Чиркәү янында гражданнар җыенын үткәрергә:

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда Аркатау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Урта Ия авылында. 2020 елның 28 ноябрендә 14.00 сәгатьтә минутта Комаров урамы буенча 13 номерлы йорт янында гражданнар җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда Урта Ия торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.3. Надеждино авылында. Гражданнар җыенын ике этапта үткәрергә:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2021 елның 30 ноябрендә 11.00 сәгатьтә Мәктәп урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Мәктәп, Яңа урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне исемлеккә кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2021 елның 30 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Мәктәп урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Космонавтлар, Яшьләр урамнары йортлары буенча исемлектә теркәлгән кешеләрне кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2022 елда Надеждино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 группа инвалидларны, эшләмәүче 2 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларны, биш һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрне бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Надеждино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге башлыгы И.З. Галәветдинов